РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘМӘШИР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422104, с.Мамашир , ул Молодежная , д.29 Б Тел./факс: (884364) 36-6-04 e-mail:Mam.kuk@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» май,2026 ел № 4

Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең иң зур күләмен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Гражданнарның аларга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын арендалау шартнамәләре буенча торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең иң зур күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен билгеләү методикасы», «2026 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2026 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 08 декабрендәге 777/пр номерлы боерыгы (Теркәлгән 30.12.2025 № 84889)», «Россия Федерациясе буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе нормативын билгеләү методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2024 елның 28 мартындагы 215/пр номерлы боерыгы (Теркәлгән 17.05.2024 № 78191)», Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьялары нигезендә ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең иң зур күләмен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәтнең түбәндәге иң зур бәясен билгеләргә.

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керем күләме иң зур күрсәткече 29 405,89 сум тәшкил итә:

1.2. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек бәясенең иң зур күләме түбәндәгечә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 065 150 сум;

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен – 2 130 300 сум;

1.2.3. Өч кешелек гаилә өчен – 3 195 450 сум;

1.2.4. Дүрт кешелек гаилә өчен – 4 260 600 сум;

1.2.5. Биш кешелек гаилә өчен – 5 325 750 сум;

1.2.6. Алты кешелек гаилә өчен – 6 390 900 сум;

1.2.7. Җиде кешелек гаилә өчен – 7 456 050 сум;

1.2.8. Сигез кешелек гаилә өчен – 8 521 200 сум.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://www Ispolkom.Kukmor@tatar.ru ) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе : И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1061675011297
ИНН 1623008634